# КАРАР

2 декабрь 2019 ел №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авылы җирлегендә Мәмәшир авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 29.11.2019 елда түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авылы, Мәмәшир авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән,90 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә риза булырсызмы?

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге,
- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,җыенда катнашучылар исемлегенә, 624 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 384.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 383 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авылында Мәмәшир җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны танырга: «2020 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Мәмәшир авылы, Мәмәшир авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 90 яшь һәм

аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге,
- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру
- -җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү,
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү
- зиратларны һәм күмү урыннарын карап тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирелеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов

ОГРН 1021607753012
ИНН 1623001702